КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 14 август г.Казань № 685

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Наркотикларга каршы өлкәдә проектларны гамәлгә ашыручы социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмаларга конкурс нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2018 ел, 18 декабрь, 1171 нче карары белән расланган Наркотикларга каршы өлкәдә проектларны гамәлгә ашыручы социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмаларга конкурс нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Наркотикларга каршы өлкәдә проектларны гамәлгә ашыручы социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмаларга конкурс нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2018 ел, 18 декабрь, 1171 нче карары белән расланган Наркотикларга каршы өлкәдә проектларны гамәлгә ашыручы социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмаларга конкурс нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

15 пунктның дүртенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«үзгәртеп кору, бетерү процессында торырга тиеш түгел, аларга карата банкротлык процедурасы кертелмәгән, субсидия алучы эшчәнлеге Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә туктатылып тормый.»;;

17 пунктта:

икенче абзацка «яки Юридик затларның бердәм дәүләт реестры язмасы битеннән» сүзләрен өстәргә;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«коммерциячел булмаган оешма җитәкчесе һәм баш хисапчысы тарафыннан имзаланган, субсидия алучы үзгәртеп кору, бетерү процессында булмавын, аңа карата банкротлык процедурасы кертелмәвен, субсидия алучы эшчәнлеге Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә туктатылмауны раслый торган гарантия хаты.»;

33 пунктның икенче абзацында «нәтиҗәлелек күрсәткечләре» сүзләрен «нәтиҗәләр» сүзенә алмаштырырга;

39 пунктта:

икенче абзацта «нәтиҗәлелек күрсәткечләре» сүзләрен «нәтиҗәләр» сүзенә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Субсидияләр алучылар Министрлыкка субсидияләр бирү елыннан соң килүче елның 1 февраленнән дә соңга калмыйча әлеге Тәртипкә кушымта нигезендә субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү турында хисап тапшыралар.»;

40 пунктның дүртенче абзацында «нәтиҗәлелек күрсәткечләре» сүзләрен «нәтиҗәләр» сүзенә алмаштырырга;

күрсәтелгән Тәртипкә кушымта өстәргә (теркәлгән).

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Наркотикларга каршы өлкәдә проектларны гамәлгә ашыручы социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмаларга конкурс нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибе кушымта (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 14 август, 685 нче карары редакциясендә)

Форма

20__ елның «__» ________ торышы буенча субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү турында хисап

Юридик затның исеме: ________________________________________

Даимилек: ________________________________________________________

| Т/с | Нәтиҗә атамасы | Проект-ның (чара) исеме | ОКЕИ буенча үлчәү берәмлеге | | Нәтиҗәгә ирешү өчен кирәкле күрсәткеч-нең пландагы мәгънәсе | Нәтиҗәгә ирешү өчен кирәкле күрсәткечнең хисап датасына ирешелгән мәгънәсе | Күрсәткеч-нең пландагы мәгънәсе үтәлеше проценты | Күрсәткеч-нең пландагы мәгънәсен-нән тайпылу-ның сәбәбе |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | исем | код | | | | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 |
| | | | | | | | | |

Юридик зат җитәкчесе
(вәкаләтле зат) _______________________ ____________ ________________
(вазыйфасы) (имза) (имзаның аңлатмасы)

Башкаручы ___________________________ ____________________ ___________
(вазыйфасы) (Ф.И.Ә.И. (соңгысы – булганда) (телефон)

«____» ________ 20__ ел

_____________________________